| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН |
|---|---|
| ***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ*** | ***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН*** |
| ***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*** | ***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*** |

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

3 октябрь 2022 ел № 2-22

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Буа шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль
хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә һәм муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, Буа шәһәр Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 29 мартындагы 1-41 номерлы Буа шәһәр Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 16 бүлек:

9 пунктчаны түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

9) Россия Федерациясе гражданлыгыннан йә чит ил гражданына муниципаль хезмәттә булу хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгыннан (подданлыгыннан) чыгу турында мәгълүм булган көнне, ләкин Россия Федерациясе гражданлыгыннан йә чит ил гражданына муниципаль хезмәттә булу хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгыннан (подданлыгыннан) чыккан көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) бу хакта язмача хәбәр итәргә

түбәндәге редакциядә 9.1 пунктчасын өстәргә:

9.1) чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алу йә яшәүгә рөхсәт яисә гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ алу турында мәгълүм булган көнне, ләкин чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алган йә яшәүгә рөхсәт яисә гражданның чит дәүләт территориясендә

даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ алган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) бу хакта язмача хәбәр итәргә;».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа шәһәре Башлыгы, Совет рәисе Р.Р. Камартдинов